КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 19 гыйнвар г.Казань № 20

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасын һәм Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетындагы вакытлыча файдаланылмый торган акчаны банк депозитларына урнаштыру тәртибе турында» 2021 ел, 3 сентябрь, 808 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты акчасын һәм Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетындагы вакытлыча файдаланылмый торган акчаны банк депозитларына урнаштыру тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасын һәм Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетындагы вакытлыча файдаланылмый торган акчаны банк депозитларына урнаштыру тәртибе турында» 2021 ел, 3 сентябрь, 808 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты акчасын һәм Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетындагы вакытлыча файдаланылмый торган акчаны банк депозитларына урнаштыру тәртибенә, 2.1 пунктның «в» пунктчасының өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Аналитик Кредит Рейтинг Агентлыгы кредит рейтинг агентлыгының (Акционерлык җәмгыяте) Россия Федерациясе өчен милли рейтинг шкаласы буенча «A-(RU)» дәрәҗәсеннән түбәнрәк булмаган, яисә «Эксперт РА» Рейтинг Агентлыгы» акционерлык җәмгыяте рейтинг агентлыгының Россия Федерациясе өчен милли рейтинг шкаласы буенча «ruA-» дәрәҗәсеннән түбәнрәк булмаган, яки «Милли

Кредит Рейтинглары» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Россия Федерациясе өчен милли рейтинг шкаласы буенча «A-.ru» дәрәҗәсеннән түбәнрәк булмаган, яки «Милли Рейтинг Агентлыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте кредит рейтинг агентлыгының Россия Федерациясе өчен милли рейтинг шкаласы буенча «A-|ru|» дәрәҗәсеннән түбәнрәк булмаган бер үк вакытта кимендә 2 кредит рейтингы булу;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин